# ЗАКОН
## Республики Татарстан

### Об общественных воспитателях несовершеннолетних

394
23 01 09

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
15 декабря 2008 года

Настоящий Закон регулирует отношения, возникающие в связи с деятельностью общественных воспитателей несовершеннолетних.

Статья 1. **Общие положения**

1. Общественный воспитатель несовершеннолетних (далее – общественный воспитатель) – гражданин Российской Федерации независимо от пола, семейного положения, по своим деловым и моральным качествам способный выполнять обязанности общественного воспитателя, быть наставником, возлагающий добровольно на себя обязанности общественного воспитателя несовершеннолетнего, находящегося в социально опасном положении или в трудной жизненной ситуации.

2. В качестве общественных воспитателей могут назначаться представители органов государственной власти и органов местного самоуправления, правоохранительных органов, органов и учреждений системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних, трудовых коллективов и общественных организаций, военнослужащие, педагогические работники.

3. Общественными воспитателями не могут быть лица:

1) признанные решением суда недееспособными или ограниченно дееспособными;

2) лишенные решением суда родительских прав или ограниченные в родительских правах;

3) отстраненные от обязанностей усыновителя, опекуна (попечителя), приемного родителя, патронатного воспитателя за ненадлежащее выполнение возложенных на них законных обязанностей;

4) не исполняющие по состоянию здоровья родительские обязанности;

5) не имеющие постоянного места жительства;

6) ранее судимые.

4. Общественный воспитатель закрепляется за несовершеннолетним, когда это будет признано необходимым комиссией по делам несовершеннолетних и защите их прав муниципального района (городского округа) (далее – комиссия по делам несовершеннолетних).

5. Общественный воспитатель выполняет обязанности на безвозмездной основе.

### Статья 2. **Цели и задачи общественных воспитателей несовершеннолетних**

1. Институт общественных воспитателей несовершеннолетних в Республике Татарстан создается в целях совершенствования социальной политики в области предупреждения безнадзорности, беспризорности и правонарушений несовершеннолетних и реализации конституционных норм по защите семьи и детства.

2. Основными задачами общественных воспитателей несовершеннолетних являются:

1) оказание помощи родителям или лицам, их заменяющим, в воспитании несовершеннолетних, находящихся в трудных жизненных ситуациях или склонных к нарушениям общественного порядка;

2) участие в осуществлении мер по защите и восстановлению прав и законных интересов несовершеннолетних в пределах своих полномочий;

3) проведение индивидуальной профилактической работы с несовершеннолетними в целях предупреждения антиобщественных действий несовершеннолетних, совершения повторных общественно опасных деяний, преступлений;

4) взаимодействие с органами и учреждениями системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних по вопросам предупреждения безнадзорности, беспризорности, правонарушений и антиобщественных действий несовершеннолетних;

5) иные задачи, установленные федеральными законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации, а также законами Республики Татарстан и иными нормативными правовыми актами Республики Татарстан.

3. Общественные воспитатели проводят свою работу в тесном контакте с родителями несовершеннолетнего (лицами, их заменяющими), органами и

учреждениями системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних, трудовыми коллективами, а также общественными организациями по месту учебы, работы или жительства несовершеннолетнего.

Статья 3. **Порядок закрепления общественных воспитателей за несовершеннолетними и работы общественных воспитателей**

1. Общественный воспитатель может закрепляться за несовершеннолетним:

1) оказавшимся в социально опасном положении или в трудной жизненной ситуации и нуждающимся в социальной помощи;

2) содержащимся в социально-реабилитационных центрах для несовершеннолетних, социальных приютах для детей и подростков, центрах помощи детям, оставшимся без попечения родителей, специальных учебно-воспитательных учреждениях, состоящим на учете в центрах (отделениях) социальной помощи семье и детям и других учреждениях для несовершеннолетних, нуждающимся в социальной помощи и (или) реабилитации;

3) употребляющим наркотические средства или психотропные вещества без назначения врача либо употребляющим одурманивающие вещества, алкогольную и спиртосодержащую продукцию, пиво и напитки, изготавливаемые на его основе;

4) совершившим общественно опасное деяние и не подлежащим уголовной ответственности в связи с недостижением возраста, с которого наступает уголовная ответственность, или вследствие отставания в психическом развитии, не связанного с психическим расстройством;

5) освобожденным от уголовной ответственности вследствие акта об амнистии или в связи с изменением обстановки;

6) условно-досрочно освобожденным от отбывания наказания, освобожденным от наказания вследствие акта об амнистии или в связи с помилованием;

7) осужденным за совершение преступления небольшой или средней тяжести и освобожденным судом от наказания с применением принудительных мер воспитательного воздействия;

8) осужденным условно, осужденным к обязательным работам, исправительным работам или иным мерам наказания, не связанным с лишением свободы;

9) освобожденным из учреждений уголовно-исполнительной системы, вернувшимся из специальных учебно-воспитательных учреждений закрытого типа, если он в период пребывания в указанных учреждениях допускал нарушения режима, совершал противоправные деяния, и (или) после освобождения (выпуска) находится в социально опасном положении, и (или) нуждается в социальной помощи и (или) реабилитации;

10) систематически самовольно уходящим из семьи или образовательных либо других детских учреждений;

11) систематически уклоняющимся от учебы;

12) безнадзорным или беспризорным;

13) занимающимся бродяжничеством или попрошайничеством;

14) другим, состоящим на учете в органах внутренних дел и в комиссии по делам несовершеннолетних, к которому необходимо применение мер общественного воздействия.

2. При назначении общественного воспитателя в каждом отдельном случае учитывается характер несовершеннолетнего, его возраст, склонности, другие обстоятельства, а также возможность и согласие самого общественного воспитателя выполнять возлагаемые на него обязанности по отношению к конкретному несовершеннолетнему.

3. Методическое руководство работой общественных воспитателей осуществляется комиссией по делам несовершеннолетних, действующей в соответствии с федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан.

4. Комиссия по делам несовершеннолетних:

1) осуществляет подбор общественного воспитателя из числа лиц, соответствующих требованиям настоящего Закона;

2) организует собеседование с кандидатами, изъявившими желание стать общественным воспитателем, при обязательном участии психолога;

3) по результатам собеседования в течение двух недель принимает решение о закреплении общественного воспитателя за несовершеннолетним с учетом мнения несовершеннолетнего, достигшего возраста десяти лет, и по согласованию с его родителями (лицами, их заменяющими);

4) организует для общественных воспитателей краткосрочные курсы общей информированности в области защиты и охраны прав детства.

5. Предложения о кандидатурах общественных воспитателей председателю комиссии по делам несовершеннолетних могут вносить депутаты Государственного Совета Республики Татарстан, депутаты представительных органов муниципальных образований, руководители органов внутренних дел, образовательных учреждений, органов и учреждений системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних, трудовых коллективов и общественных организаций, а также члены комиссии по делам несовершеннолетних.

6. Комиссия по делам несовершеннолетних выдает общественному воспитателю решение о закреплении его общественным воспитателем за несовершеннолетним и памятку, в которой излагаются права и обязанности общественного воспитателя, а также удостоверение общественного воспитателя, порядок выдачи и образец которого утверждаются Республиканской ко-

миссией по делам несовершеннолетних при Кабинете Министров Республики Татарстан.

7. Комиссия по делам несовершеннолетних в пятидневный срок после дня принятия решения о закреплении общественного воспитателя за несовершеннолетним сообщает по месту работы общественного воспитателя, родителям несовершеннолетнего или лицам, их заменяющим, о принятом решении, в котором в соответствии с законодательством с письменного согласия общественного воспитателя указываются его фамилия, имя, отчество, номера контактных телефонов, место работы и жительства.

8. Комиссия по делам несовершеннолетних совместно с общественным воспитателем разрабатывает индивидуальную программу реабилитации несовершеннолетнего и план мероприятий по ее реализации, которые утверждаются председателем комиссии по делам несовершеннолетних и согласуются с главой муниципального образования.

9. По обращению общественного воспитателя муниципальное образование в пределах своей компетенции организует оказание несовершеннолетнему медицинской, психолого-педагогической, социально-правовой, социально-бытовой и иных видов помощи.

10. Координацию деятельности комиссии по делам несовершеннолетних в части методического руководства работой общественных воспитателей осуществляет Республиканская комиссия по делам несовершеннолетних при Кабинете Министров Республики Татарстан.

11. Работа общественного воспитателя прекращается в случае:

1) выполнения общественным воспитателем обязательств по оказанию помощи несовершеннолетнему при достижении им 18-летнего возраста;

2) замены его другим общественным воспитателем;

3) при выезде несовершеннолетнего на другое место жительства;

4) при снятии несовершеннолетнего с учета в органах внутренних дел и в комиссии по делам несовершеннолетних;

5) по личной просьбе общественного воспитателя, несовершеннолетнего или его родителей (лиц, их заменяющих);

6) иных случаях, не предусмотренных настоящим Законом, по решению комиссии по делам несовершеннолетних.

12. Решение о прекращении гражданином деятельности в качестве общественного воспитателя принимает комиссия по делам несовершеннолетних.

Статья 4. **Обязанности общественного воспитателя**

Общественный воспитатель обязан:

1) в пределах своих полномочий оказывать родителям или лицам, их заменяющим, помощь в исполнении ими обязанностей по воспитанию и обучению несовершеннолетнего;

2) прилагать усилия для исправления несовершеннолетнего, искоренения имеющихся у него вредных привычек и проявлений аморального поведения, для подготовки его к осознанной общественно полезной деятельности;

3) принимать меры для получения несовершеннолетним образования, содействовать регулярному посещению несовершеннолетним общеобразовательного учреждения, наблюдать за его успеваемостью, поведением в школе, на работе, в семье, на улице, в общественных местах;

4) оказывать содействие несовершеннолетнему в трудоустройстве и временной занятости;

5) оказывать помощь несовершеннолетнему в более эффективном использовании свободного от посещения общеобразовательного учреждения времени: привлекать его к занятиям во внешкольных учреждениях и организациях;

6) принимать меры к созданию надлежащих условий для правильной организации учебы, труда и досуга несовершеннолетнего;

7) способствовать формированию у несовершеннолетнего навыков общения, поведения, правосознания, правовой культуры;

8) оказывать содействие в формировании морально-нравственных ценностей, патриотизма и гражданской культуры;

9) прививать несовершеннолетнему чувство ответственности перед обществом и государством;

10) оказывать содействие в урегулировании конфликтов, возникающих между несовершеннолетним и членами его семьи;

11) при необходимости информировать комиссию по делам несовершеннолетних о наличии конфликтов, разногласий, противоречий между несовершеннолетним и родителями (лицами, их заменяющими).

Статья 5. **Права общественного воспитателя**

Общественный воспитатель имеет право:

1) посещать несовершеннолетнего по месту жительства, учебы или работы;

2) давать несовершеннолетнему необходимые советы по соблюдению правил поведения;

3) обращать внимание родителей (лиц, их заменяющих) на ненадлежащее выполнение ими родительских обязанностей, разъяснять их ответственность за поведение несовершеннолетнего;

4) вносить вопрос на обсуждение комиссии по делам несовершеннолетних о неудовлетворительном выполнении родителями (лицами, их заменяющими) обязанностей по воспитанию детей, об обсуждении их поведения на заседании комиссии и принятии других мер воздействия в случае неодно-

кратного невыполнения его требований либо отсутствия положительных результатов в перевоспитании несовершеннолетнего;

5) содействовать несовершеннолетнему в организации его досуга, продолжении учебы, получении медицинского обслуживания, проведении систематического осмотра врачами-специалистами в соответствии с медицинскими рекомендациями и состоянием здоровья;

6) принимать меры по защите прав и законных интересов несовершеннолетнего;

7) участвовать в работе комиссии по делам несовершеннолетних при рассмотрении вопросов, затрагивающих права несовершеннолетнего, по отношению к которому является общественным воспитателем;

8) получать в соответствии с законодательством от органов внутренних дел и учреждений системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних необходимую информацию о несовершеннолетнем и его родителях (лицах, их заменяющих), связанную с исполнением обязанностей общественного воспитателя;

9) получать в соответствии с законодательством от органов внутренних дел и учреждений системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних необходимую помощь и содействие в реализации индивидуальной программы реабилитации несовершеннолетнего, связанные с исполнением обязанностей общественного воспитателя.

Статья 6. **Меры поощрения общественных воспитателей**

1. Общественные воспитатели, активно и добросовестно исполняющие свои обязанности, добившиеся положительных результатов в работе с несовершеннолетними, по представлению комиссии по делам несовершеннолетних могут поощряться органами государственной власти, органами местного самоуправления, организациями по месту их работы или учебы.

2. В соответствии с законодательством формы и порядок поощрения общественных воспитателей могут устанавливаться Кабинетом Министров Республики Татарстан, органами местного самоуправления, общественными организациями, коллективами по месту работы или учебы общественного воспитателя.

Статья 7. **Замена общественного воспитателя**

1. В случае неисполнения или ненадлежащего исполнения общественным воспитателем своих обязанностей комиссия по делам несовершеннолетних по ходатайству органов и учреждений системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних, несовершеннолетнего, его родителей (лиц, их заменяющих) либо по собственной инициативе принимает

решение об отстранении гражданина от исполнения обязанностей общественного воспитателя.

2. При необходимости несовершеннолетнему может быть назначен другой общественный воспитатель в порядке, установленном статьей 3 настоящего Закона.

Статья 8. **Права несовершеннолетних**

Несовершеннолетним, в отношении которых проводится индивидуальная профилактическая работа с участием общественного воспитателя, обеспечиваются права и свободы, гарантированные международными правовыми актами, Конституцией Российской Федерации, Конституцией Республики Татарстан, Федеральным законом от 24 июля 1998 года № 124-ФЗ «Об основных гарантиях прав ребенка в Российской Федерации», Федеральным законом от 24 июня 1999 года № 120-ФЗ «Об основах системы профилактики безнадзорности и правонарушений несовершеннолетних», другими законами и иными нормативными правовыми актами Российской Федерации и Республики Татарстан.

Статья 9. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу через десять дней после дня его официального опубликования.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои нормативные правовые акты в соответствие с настоящим Законом, а также принять нормативные правовые акты, обеспечивающие его реализацию.

Президент
Республики Татарстан — М.Ш.Шаймиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань,Кремль
2I января 2009 года
№ 7-ЗРТ

# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында

23 07 394 09

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2008 елның 15 декабрендә
кабул ителде

Әлеге Закон балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре эшчәнлегенә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала.

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

1. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячесе (алга таба – җәмәгать тәрбиячесе) – җенесенә, гаилә хәленә бәйсез рәвештә, үзенең эшлекле һәм әхлакый сыйфатлары буенча җәмәгать тәрбиячесе вазыйфаларын үтәргә, остаз булырга сәләтле, социаль куркыныч хәлдә яисә авыр тормыш шартларында булган балигъ булмаганның җәмәгать тәрбиячесе вазыйфаларын ирекле рәвештә үз өстенә алучы Россия Федерациясе гражданы.

2. Җәмәгать тәрбиячеләре булып дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының, хокук саклау органнарының, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең, хезмәт коллективларының һәм иҗтимагый оешмаларның вәкилләре, хәрби хезмәткәрләр, педагогика хезмәткәрләре билгеләнеп куелырга мөмкин.

3. Түбәндәге затлар җәмәгать тәрбиячеләре була алмый:

1) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылган;

2) суд тарафыннан ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән яисә ата-ана хокуклары чикләнгән;

3) үзләренә йөкләнгән законлы бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен уллыкка (кызлыкка) алучы, опекун (попечитель), тәрбиягә бала алган ата-ана, патронат тәрбияче вазыйфаларыннан читләштерелгән;

4) сәламәтлеге аркасында ата-ана бурычларын үтәмәгән;

5) даими яшәү урыны булмаган;

6) элек хөкем ителгән затлар.

4. Балигъ булмаганга җәмәгать тәрбиячесе муниципаль районның (шәһәр округының) балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе (алга таба – балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе) тарафыннан кирәк дип танылганда беркетелә.

5. Җәмәгать тәрбиячесе үз вазыйфаларын түләүсез башкара.

2 статья. **Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең максатлары һәм бурычлары**

1. Татарстан Республикасында балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре институты балигъ булмаганнарның күзәтүчесез, караучысыз калуын һәм хокук бозуларын кисәтү өлкәсендә социаль сәясәтне камилләштерү, гаиләне һәм балаларны яклау буенча конституциячел нормаларны гамәлгә ашыру максатларында төзелә.

2. Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләренең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

1) авыр тормыш шартларында булган яисә җәмәгать тәртибен бозуга омтылышлы балигъ булмаганнарны тәрбияләүдә ата-аналарга яисә аларны алыштыручы затларга ярдәм итү;

2) балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу буенча чараларны гамәлгә ашыруда үз вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

3) балигъ булмаганнарның җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуларын, җәмгыяви куркыныч гамәлләрне, җинаятьләрне кабат кылуларын кисәтү максатларында балигъ булмаганнар белән индивидуаль профилактик эш уздыру;

4) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре белән берлектә балигъ булмаганнарның күзәтүчесез, караучысыз калуын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуларын кисәтү мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү;

5) федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, шулай ук Татарстан Республикасы законнарында һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән бүтән бурычлар.

3. Җәмәгать тәрбиячеләре үз эшләрен балигъ булмаганның ата-анасы (аларны алыштыручы затлар), балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм

учреждениеләре, хезмәт коллективлары, шулай ук балигъ булмаганның уку, эш яисә яшәү урыны буенча иҗтимагый оешмалар белән тыгыз бәйләнештә башкаралар.

3 статья. **Балигъ булмаганнарга җәмәгать тәрбиячеләрен беркетү һәм җәмәгать тәрбиячеләренең эшләү тәртибе**

1. Җәмәгать тәрбиячесе түбәндәге балигъ булмаганга беркетелә:

1) социаль куркыныч хәлдә яисә авыр тормыш шартларында калган һәм социаль ярдәмгә мохтаҗ;

2) балигъ булмаганнар өчен социаль-реабилитация үзәкләрендә, балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютларда, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга ярдәм итү үзәкләрендә, махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрендә торучы, гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү үзәкләрендә (бүлекчәләрендә) һәм социаль ярдәмгә һәм (яисә) реабилитацияләүгә мохтаҗ булган балигъ булмаганнар өчен башка учреждениеләрдә исәптә торучы;

3) табиб билгеләвеннән башка наркотик чаралар яисә психотроп матдәләр кулланучы йә миңгерәткеч матдәләр, алкогольле һәм спиртлы продукция, сыра һәм аның нигезендә әзерләнә торган эчемлекләр кулланучы;

4) җәмгыяви куркыныч гамәл кылган һәм җинаять җаваплылыгы билгеләнә торган яшькә җитмәү аркасында яисә психик кимчелеккә бәйле булмаган рәвештә психик үсеше тоткарлану нәтиҗәсендә җинаять җаваплылыгына җәлеп ителми торган;

5) амнистия турындагы акт нәтиҗәсендә яисә шартлар үзгәрүгә бәйле рәвештә җинаять җаваплылыгыннан азат ителгән;

6) җәза узудан шартлы-вакытыннан алда азат ителгән, амнистия турындагы акт нәтиҗәсендә яисә ярлыкауга бәйле рәвештә җәзадан азат ителгән;

7) авыр булмаган яисә уртача авырлыкта җинаять кылган өчен хөкем ителгән һәм тәрбияви йогынтылы мәҗбүри чаралар белән җәзадан суд тарафыннан азат ителгән;

8) шартлы рәвештә хөкем ителгән, мәҗбүри эшләргә, төзәтү эшләренә яисә иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган башка җәза чараларына хөкем ителгән;

9) җинаять-башкару системасы учреждениеләреннән азат ителгән, ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләреннән кайткан, әгәр ул күрсәтелгән учреждениеләрдә булу чорында режимны бозган, хокукка каршы гамәлләр кылган булса, һәм (яисә) азат ителгәннән соң (чыгарылганнан соң) социаль куркыныч хәлдә булса, һәм (яисә) социаль ярдәмгә һәм (яисә) реабилитацияләүгә мохтаҗ булса;

10) гаиләдән яисә мәгариф йә башка балалар учреждениеләреннән даими рәвештә рөхсәтсез китеп йөргән;

11) даими рәвештә укудан читләшкән;

12) күзәтүчесез яисә караучысыз калган;

13) сукбайлык яисә теләнү белән шөгыльләнүче;

14) эчке эшләр органнарында һәм балигъ булмаганнар эшләре комиссиясендә исәптә торучы, җәмәгать йогынтысы чараларын куллану кирәк булган башка балигъ булмаган затка.

2. Җәмәгать тәрбиячесен билгеләгәндә һәр аерым очракта балигъ булмаганның характеры, аның яше, омтылышлары, башка шартлар, шулай ук җәмәгать тәрбиячесенең конкрет балигъ булмаган затка карата үзенә йөкләнә торган бурычларны үтәү мөмкинлеге һәм үз ризалыгы исәпкә алына.

3. Җәмәгать тәрбиячеләренең эшенә методик җитәкчелек итү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлдә булучы балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе тарафыннан башкарыла.

4. Балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе:

1) әлеге Закон таләпләренә туры килә торган затлар арасыннан җәмәгать тәрбиячесен сайлап ала;

2) җәмәгать тәрбиячесе булырга теләгән кандидатлар белән психологның катгый катнашуында әңгәмә оештыра;

3) ун яшькә җиткән балигъ булмаганның фикерен искә алып һәм аның ата-анасы (аларны алыштыручы затлар) белән килештереп, әңгәмә нәтиҗәләре буенча ике атна эчендә җәмәгать тәрбиячесен балигъ булмаганга беркетү турында карар кабул итә;

4) җәмәгать тәрбиячеләре өчен балаларның хокукларын яклау һәм саклау өлкәсендә гомуми мәгълүматлылык буенча кыска сроклы курслар оештыра.

5. Җәмәгать тәрбиячеләре кандидатуралары турындагы тәкъдимнәрне балигъ булмаганнарның эшләре комиссиясе рәисенә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары депутатлары, эчке эшләр органнарының, мәгариф учреждениеләренең, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең, хезмәт коллективларының һәм иҗтимагый оешмаларның җитәкчеләре, шулай ук балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе әгъзалары кертергә мөмкин.

6. Балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе җәмәгать тәрбиячесенә аны балигъ булмаганга җәмәгать тәрбиячесе итеп беркетү турындагы карарны һәм җәмәгать тәрбиячесенең хокуклары һәм бурычлары бәян ителгән памятканы, шулай ук бирү тәртибе һәм үрнәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе тарафыннан раслана торган җәмәгать тәрбиячесе таныклыгын бирә.

7. Балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе җәмәгать тәрбиячесен балигъ булмаганга беркетү турында карар кабул ителгән көннән соң биш көн эчендә җәмәгать тәрбиячесенең эш урынына, балигъ булмаганның ата-анасына яисә аларны алыштыручы затларга кабул ителгән карар турында

хәбәр итә, анда җәмәгать тәрбиячесенең ризалыгы белән законнар нигезендә җәмәгать тәрбиячесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, элемтә өчен телефон номерлары, эш урыны һәм яшәү урыны күрсәтелә.

8. Балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе җәмәгать тәрбиячесе белән бергә балигъ булмаганны реабилитацияләүнең индивидуаль программасын һәм аны гамәлгә ашыру чаралары планын эшли, алар балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе рәисе тарафыннан раслана һәм муниципаль берәмлек башлыгы белән килештерелә.

9. Муниципаль берәмлек җәмәгать тәрбиячесе мөрәҗәгате буенча балигъ булмаганга медицина, психологик-педагогик, социаль-хокукый, социаль-көнкүреш һәм бүтән төрле ярдәм күрсәтүне үз компетенциясе чикләрендә оештыра.

10. Балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе эшчәнлеген җәмәгать тәрбиячеләре эшенә методик җитәкчелек итү өлешендә координацияләүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча республика комиссиясе гамәлгә ашыра.

11. Җәмәгать тәрбиячесенең эше түбәндәге очракларда туктатыла:

1) җәмәгать тәрбиячесе тарафыннан балигъ булмаганга ярдәм итү йөкләмәләре аңа 18 яшь тулгач үтәлгәндә;

2) аны башка җәмәгать тәрбиячесе белән алыштырганда;

3) балигъ булмаган зат башка яшәү урынына күчеп киткәндә;

4) балигъ булмаган зат эчке эшләр органнарында һәм балигъ булмаганнар эшләре комиссиясендә исәптән төшерелгәндә;

5) җәмәгать тәрбиячесенең, балигъ булмаганның яисә аның ата-анасының (аларны алыштыручы затларның) шәхси үтенече буенча;

6) әлеге Законда каралмаган башка очракларда балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе карары буенча.

12. Гражданның җәмәгать тәрбиячесе буларак эшчәнлеген туктату турындагы карарны балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе кабул итә.

4 статья. **Җәмәгать тәрбиячесе бурычлары**

Җәмәгать тәрбиячесе түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) ата-анага яисә аларны алыштыручы затларга балигъ булмаганны тәрбияләү һәм укыту бурычларын үтәгәндә үз вәкаләтләре чикләрендә ярдәм итәргә;

2) балигъ булмаганны төзәтү, анда булган яман гадәтләрне һәм әдәпсезлек күренешләрен бетерү, аны аңлы рәвештә җәмгыятькә файдалы эшчәнлеккә әзерләү өчен көч куярга;

3) балигъ булмаган зат белем алсын өчен чаралар күрергә, балигъ булмаганга гомуми белем бирү учреждениесенә даими рәвештә йөрүдә ярдәм итәргә, аның укудагы өлгерешен, мәктәптәге, эштәге, гаиләдәге, урамдагы, җәмәгать урыннарындагы тәртибен күзәтергә;

4) балигъ булмаганга эшкә урнашуда һәм аның вакытлыча шөгыльләнүенә ярдәм итәргә;

5) балигъ булмаганга гомуми белем бирү учреждениесенә йөрүдән буш вакытын нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәргә: аны мәктәптән тыш учреждениеләрдәге һәм оешмалардагы шөгыльләргә җәлеп итәргә;

6) балигъ булмаганның укуын, хезмәтен һәм ял итүен дөрес оештыру өчен тиешле шартлар тудыру өчен чаралар күрергә;

7) балигъ булмаган затта аралашу, холык-фигыль, хокукый гыйлем, хокукый культура күнекмәләрен барлыкка китерүдә ярдәм итәргә;

8) мораль-әхлакый кыйммәтләрне, патриотизмны һәм граждан культурасын булдыруда ярдәм итәргә;

9) балигъ булмаганга җәмгыять һәм дәүләт алдында җаваплылык хисе сеңдерергә;

10) балигъ булмаган зат һәм аның гаилә әгъзалары арасында барлыкка килә торган конфликтларны җайга салуда ярдәм итәргә;

11) кирәк чакта балигъ булмаганнар эшләре комиссиясенә балигъ булмаган зат белән ата-анасы (аларны алыштыручы затлар) арасындагы конфликтлар, каршылыклар, үзара килешмәүчәнлекләр булу турында хәбәр итәргә.

5 статья. **Җәмәгать тәрбиячесе хокуклары**

Җәмәгать тәрбиячесе түбәндәгеләргә хокуклы:

1) балигъ булмаганның яшәү, уку яисә эш урынына барып йөрергә;

2) балигъ булмаганга тәртип кагыйдәләрен үтәү буенча кирәкле киңәшләр бирергә;

3) ата-ананың (аларны алыштыручы затларның) ата-ана бурычларын тиешенчә үтәмәүләренә игътибар итәргә, балигъ булмаганның тәртибе өчен аларның җаваплы булуларын аңлатырга;

4) ата-ананың (аларны алыштыручы затларның) балаларын тәрбияләү бурычларын канәгатьләнмәслек итеп үтәүләре турындагы, аларның тәртипләрен комиссия утырышында тикшерү турындагы һәм җәмәгать тәрбиячесе таләпләрен берничә мәртәбә үтәмәгән йә балигъ булмаганны тәрбияләүдә уңай нәтиҗә булмаган очракта башка йогынты чараларын күрү турындагы мәсьәләне балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе тикшерүенә чыгарырга;

5) балигъ булмаганга аның ялын оештыруда, укуын дәвам итүдә, аңа медицина хезмәте күрсәтүдә, медицина күрсәтмәләре һәм сәламәтлек торышы нигезендә белгеч табиблар тарафыннан даими рәвештә тикшерү үткәрүдә ярдәм күрсәтергә;

6) балигъ булмаганның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау чараларын күрергә;

7) балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе эшендә җәмәгать тәрбиячесе карамагындагы балигъ булмаганның хокукларына кагылышлы мәсьәләләрне караганда катнашырга;

8) эчке эшләр органнарыннан һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләреннән балигъ булмаган зат турында һәм аның ата-анасы (аларны алыштыручы затлар) турында җәмәгать тәрбиячесе вазыйфаларын үтәүгә бәйле кирәкле мәгълүматны законнар нигезендә алырга;

9) балигъ булмаган затны реабилитацияләүнең индивидуаль программасын гамәлгә ашыруда эчке эшләр органнарыннан һәм балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы учреждениеләреннән җәмәгать тәрбиячесе вазыйфаларын үтәүгә бәйле кирәкле ярдәмне законнар нигезендә алырга.

6 статья. **Җәмәгать тәрбиячеләрен кызыксындыру чаралары**

1. Үз вазыйфаларын актив һәм намуслы башкаручы, балигъ булмаганнар белән эшләгәндә уңай нәтиҗәләргә ирешкән җәмәгать тәрбиячеләре балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе тәкъдиме буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, эш яисә уку урыны буенча оешмалар тарафыннан бүләкләнергә мөмкин.

2. Җәмәгать тәрбиячеләрен кызыксындыру рәвешләре һәм тәртибе законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый оешмалар, җәмәгать тәрбиячесенең эш яисә уку урыны буенча коллективлар тарафыннан билгеләнергә мөмкин.

7 статья. **Җәмәгать тәрбиячесен алмаштыру**

1. Җәмәгать тәрбиячесе үзенең бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, балигъ булмаганнар эшләре комиссиясе балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарының һәм учреждениеләренең, балигъ булмаган затның, аның ата-анасының (аларны алыштыручы затларның) үтенечнамәсе йә үз инициативасы белән гражданны җәмәгать тәрбиячесе бурычларын үтәүдән азат итү турында карар кабул итә.

2. Кирәк очракта балигъ булмаганга әлеге Законның 3 статьясында билгеләнгән тәртиптә башка җәмәгать тәрбиячесе билгеләнеп куела.

8 статья. **Балигъ булмаганнарның хокуклары**

Җәмәгать тәрбиячесе катнашында үзенә карата индивидуаль профилактика эше алып барыла торган балигъ булмаганнарга халыкара хокук актлары, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы

Конституциясе, "Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында" 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон, "Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында" 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән гарантияләнгән хокуклар һәм ирекләр тәэмин ителә.

9 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң ун көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга яраклаштырырга, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ПРЕЗИДЕНТ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2009 елның 21 гыйнвары

№ 7-ТРЗ